**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОДАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**IV ЧАКЫРЫЛЫШ**

**УНҖИДЕНЧЕ СЕССИЯ**

**КАРАР № 1**

Кодаш авыл ж. 09 февраль 2022 ел

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмә хакында»гы 2019елның 14 октябрендә узган 46 сессиясенең 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә

**Кодаш авыл җирлеге Советы**

**Карар итте:**

«Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә бюджет процессы хакында Нигезләмә турында»гы Кодаш авыл җирлеге Советы 46 нчы сессиясенең 6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә» :

1.1 статьяда 4:

- 10 пунктның 2, 3 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

(2 пункт 2013 елның 16 октябрендәге 79-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы редакциясендә) 2) бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрне, бюджетның бердәм счетындагы калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш, планлаштыруны (фаразлауны) гамәлгә ашыра.;

3) бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын түләү өчен бүлеп бирелгән ассигнованиеләрне файдалануның адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә;»;

- 11 пунктның 1, 2 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

1) бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрне, бюджетның бердәм счетындагы калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш, планлаштыруны (фаразлауны) гамәлгә ашыра;

2) бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының бюджетка керүләренең тулылыгын һәм үз вакытында булуын контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә һәм басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Кодаш авыл җирлеге башлыгы Г. Ә. Хәйсарова**